Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлегенең
Кәләй тимер юл станциясе бистәсе гражданнар җыены нәтиҗәләре
турындагы карары

31 октябрь 2025 ел № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 31 октябрендә 09 сәгать 00 минутта, 10 сәгать 00 минутта, 11 сәгать 00 минутта, 12 сәгать 00 минутта, 17 сәгать 00 минутта булган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл җирлеге Кәләй тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 нче группа инвалидлардан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (тимер юл урамындагы су насослары станциясе бинасын ремонтлау) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу/юлларга асфальт салу, асфальт юллардагы чокырларны ремонтлау, юлларга вак таш салу)?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1704 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 932 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 895 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 37 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлегенең Кәләй тимер юл станциясе бистәсе гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлеге Кәләй тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 нче группа инвалидлардан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм су

агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (Тимер юл урамындагы су насослары станциясе бинасын ремонтлау, Зеленая урамындагы скважинаны төзеклендерү) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу/юлларга асфальт салу, асфальт юллардагы чокырларны ремонтлау, юлларга вак таш салу)?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы, 38б йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Кәләй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урман- Кәләй авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев